СОВЕТ КРАСНОГОРСКОГО СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ МАМАДЫШСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН
ул.Мира, д.11А, п.с-за “Мамадышский”,
Мамадышский район,
Республика Татарстан, 422165

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ МАМАДЫШ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ КЫЗЫЛ ТАУ АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ СОВЕТЫ
Мира ур., 11А нче йорт, “Мамадыш” совхозы поселогы, Мамадыш районы,
Татарстан Республикасы,422165

тел.(факс): (85563) 3-91-14; e-mail: KrGor.Mam@tatar.ru, www:mamadysh.tatarstan.ru

Решение
«22» июня 2020 г.

Карар
№5-53

Бер мандатлы сайлау округлары тасвирламасын төгәлләштерү турында

«Россия Федерациясе гражданнарының сайлау хокукларының һәм референдумда катнашу хокукының төп гарантияләре турында» 2002 елның 12 июнендәге 67-ФЗ номерлы Федераль законның 18 статьясына, Татарстан Республикасы Сайлау кодексының 2007 елның 7 маендагы 21-ТРЗ номерлы 26 статьясына, яңа йортлар файдалануга кертелүгә бәйле рәвештә, Татарстан Республикасы Мамадыш муниципаль районы Кызыл Тау авыл җирлеге Советы КАРАР ИТТЕ:

1. Татарстан Республикасы Мамадыш муниципаль районы Кызыл Тау авыл җирлеге Советының 2015 елның 30 апрелендәге 3-26 номерлы карары белән расланган өченче чакырылыш Татарстан Республикасы Мамадыш муниципаль районы Кызыл Тау авыл җирлеге Советына депутатлар сайлауларын үткәрү өчен сайлау округлары схемасын кертү:

4 нче Кызыл Тау сайлау округына Урман, Яңа, Чәчәкле, Кояшлы, Привражная, Урман, Чәчәкле, Яңа "Мамадыш" совхозы поселогы-тулысынча;

6 нчы номерлы Кызыл Тау сайлау округы: «Мамадыш» совхозының Мәктәп урамы буенча 15,16 А,17,18 нче йортлар.

2. Әлеге карарны Мамадыш муниципаль районының рәсми сайтында, “Интернет” мәгълүмати- коммуникацион челтәрендәге Татарстан Республикасының муниципаль берәмлекләр Порталында (http://mamadysh.tatarstan.ru/) һәм Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында (http://pravo.tatarstan.ru), «Нократ» («Вятка») район газетасында бастырып чыгарып, Татарстан Республикасы Мамадыш муниципаль районы Кызыл Тау авыл җирлегенең мәгълүмат стендларында урнаштырып халыкка игълан итәргә.

Башлык,
Мамадыш муниципаль районы
Кызыл Тау авыл җирлеге Советы рәисе /В.А. Гыйzзәтулина/